АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2026 п.г.т. Алексеевское 51

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 15.11.2021 ел, № 73 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатында Алексеевск районы прокуратурасының 09.03.2026 елгы 02-08-01/26 номерлы протестын карап

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 73 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- 3.3.5. нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.5. Контроль органына ризасызлыклар контрольдә тотылучы зат тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда гади электрон имза яисә көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Контроль органның кисәтүендә күрсәтелгән электрон почта адресына йә бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә кәгазь документ рәвешендә почта адресына җибәрелә.»;

- 3.5.2. нче пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны

үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.»;

- 3.5.3 пунктының 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:

«11) контрольдә тотылучы зат әлеге Нигезләмәнең 3.5.3 пунктының 1 пунктчасында каралган критерийларга туры килми.»;

- 4.1.4. нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.4. Планлы һәм планнан тыш контроль чаралар, контрольдә тотылучы затлар белән үзара хезмәттәшлексез уздырылучылардан тыш, инспектор һәм контроль чарасын уздыруга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан түбәндәге контроль гамәлләр башкару юлы белән уздырыла:

1) карау;

2) тикшерү;

3) сораштыру;

4) язма аңлатмалар алу;

5) документларны таләп итү;

6) пробалар (үрнәкләр)алу;

7) инструменталь тикшерү;

8) сынау;

9) экспертиза;

10) эксперимент.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Сафина Г.Т.).

**Муниципаль район Башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**